

Бу авылда тырыш халык яши. Темников районы Тархан авылыннан фермер Наиль Шакир улы Кутыев турында ул жирдән яралган - от земли, диләр: авылда vскән, крестьян гаиләсендә тәрбияләнгән һәм авыл хужалыгындагы бетмәс-токәнмәс эшсез тормышын анын kvз алдына да китереп булмый, дип әйтергә була.
Тархан колхозында хезмәт эшчән-леген армиягә кадәр vк башлаган язма героебыз. Хезмәттән сон биредә 30 ел машина йортvче, ферма модире, бригадир булып эшләгән. 2011 елда vгезләр симертv буенча vз фермер хужалыгын оештырган, ә бер елдан сон яна эш башлаучы фермер буларак, ярдәмгә Грант алган. Шул акчага утыз баш яшь терлек сатып алган.

Шулай итеп, Наиль Шакир улы vгезләрне бер елга кадәр ашата, аннары итне тере авырлык белән сата. Фермернын экологик чиста продукциясен районнан читтә дә беләләр. Мәскәv, Санкт-Петербург, Саров халкы сатып ала, икән. Ит сатып алуга язылу - ярты ел алдан.
Наиль Шакир улы эре могезле терлек vстерvдә ин моһиме - яхшы азык, ди. Яз һәм жәйләрнен, малларга азык әзерләv вакытында, һәр аяз коннән файдаланып калырга тырыша ул. Бу вакытта Санкт-Петербургтан әтисенә ярдәмгә анын ике улы килә. Алар печән чабарга, жыярга ярдәм итәләр. Кутыевлар гаиләсе улларын ихтирамлы һәм авыл хезмәтенә битараф булмаган кешеләр итеп тәрбияләvдән бик канәгать. Икесе дә кечкенәдән авыр крестьян хезмәтен vзләштереп vскәннәр; бvген дә йорт эшләрендә ярдәм итәргә тырышалар. Фермер хужалыгы очен алар, әтиләре белән бергә, пресс-подборщик белән роторлы чапкыч та сатып алганнар.
Наиль Шакировичнын фермерлык эшендә зур ярдәмне тормыш иптәше, жирле китапханәче булып хезмәт иткән хатыны, Фәридә Фәрит кызы kvрсәтә. Нәкъ менә терлекләргә азык әзерләv вакытында ул ялга чыгарга тырыша.
Хужалык белән эшләv кыенмы, дигән «Темников хәбәрләре» корреспонденты соравына Наиль Шакир улы Кутыев болай дигән: «Ә хәзер кайда жинел?! Тормышта шулай жинел берни дә бирелми. Kvп хезмәт һәм коч куйсан, kvп акча да алырсын».
Фермер Наиль Шакир улы Кутыев кече ватанында калып, мал-туар vстереп, жир чәчеп, тырыш хезмәте аркасында унышка ирешергә момкин дигәнгә бик матур vрнәк. Авылда эш катлаулы, әмма рәхмәтле.

Наилә Насырова